СОВЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18.11.2019** **с. Ерыкла** **№105**

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зирекле авыл җирлеге советының**
**17.11.2018 ел 76 нче номерлы**
**“Җир салымы турындагы ”**
**карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, шул исәптән«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 75 пунктының «а " пунктчасындагы үзгәрешләр нигезендә

**Зирекле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге советының 17.11.2018 ел 76 нче номерлы “Җир салымы турындагы”карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасындагы 2 абзацына «( индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган(бирелгән) ,әмма эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш)»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында рәсми басылып чыккан көннән,бер айдан да иртә булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карар үз көченә кергәннән соң, Зирекле авыл җирлеге Советының җир салымы турындагы карары һәм бу карарларга 2018 елга кадәр кабул ителгән үзгәрешләр кертү турындагы карарларын үз кочен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет “мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зирекле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **В.А.Данилова**